**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлеге Советы**

**№165** **20.05.2020 ел**

**"2019 елда Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлеге бюджеты**
**үтәлеше турында"**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Уставының 47,76,77,81 статьялары нигезендә, Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Советы

**карар бирә:**

1. 2019 ел өчен Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 7641,9 мең сум, чыгымнар буенча 7687,3 мең сум, керемнәрне чыгымнардан 45,4 мең сумга арттырып, һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1.1. 2019 ел өчен бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә;

1.2. 2019 ел өчен бюджет керемнәре буенча әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә;

1.3. тармак структурасы буенча бюджет чыгымнарын 3нче кушымта нигезендә һәм чыгымнарның функциональ структурасы бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре буенча 2019 ел өчен бюджет чыгымнарын бүлүне әлеге карарга 4нче кушымта нигезендә.

2. 5нче кушымта нигезендә Яңа Спас авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турында исәпкә алырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Спас авыл җирлеге Советы
рәисе урынбасары А.С.Быля